КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 май г.Казань № 387

Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән, шулай ук федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган, Татарстан Республикасы бюджетында муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидия рәвешендә каралган акча белән баш эш итүче итеп билгеләргә һәм аңа Дәүләт про-

граммасының түбәндәге чараларын тормышка ашыру өчен җаваплылык йөкләргә:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча;

торак урынны наемга алу шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү буенча;

авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру буенча;

авыл территорияләрендә компактлы торак йортлар салу өчен мәйданчыкларны комплекслы тәртипкә китерү проектларын тормышка ашыру буенча.

3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шулай ук федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акча белән баш эш итүче итеп билгеләргә һәм аңа Дәүләт программасының түбәндәге чараларын тормышка ашыру өчен җаваплылык йөкләргә:

авыл территорияләрендә газлаштыруны һәм су белән тәэмин итүне үстерү буенча;

авыл территорияләрендә компактлы торак йортлар салу өчен мәйданчыкларны комплекслы тәртипкә китерү проектларын тормышка ашыру буенча;

компактлы торак йортлар салу өчен авыл территорияләрендә урнашкан мәйданчыкларны инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм төзекләндерү проектларын тормышка ашыру буенча;

авыл территорияләрен һәм авыл агломерацияләрен комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыру буенча.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгеләгән вакытларда аңа бу карарның 3 нче пунктында күрсәтелгән акчаны файдалану турында хисап кертергә.

5. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, шулай ук федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акча белән баш эш итүче итеп билгеләргә һәм аңа Дәүләт программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларының иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү буенча чараларын тормышка ашыру өчен җаваплылык йөкләргә.

6. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгеләгән вакытларда аңа бу карарның 5 нче пунктында күрсәтелгән акчаны файдалану турында хисап кертергә.

7. Дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру эшләренең дәүләт заказчылары итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне һәм газлаштыруны үстерү, авыл территорияләрендә компактлы торак йортлар салу өчен мәйданчыкларны комплекслы тәртипкә китерү проектларын тормышка ашыру, компактлы торак йортлар салу өчен авыл территорияләрендә урнашкан мәйданчыкларны инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм төзекләндерү проектларын тормышка ашыру, авыл территорияләрен һәм авыл агломерацияләрен комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыру буенча – «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесен;

авыл территорияләрендә компактлы торак йортлар салу өчен мәйданчыкларны комплекслы тәртипкә китерү проектларын тормышка ашыру, компактлы торак йортлар салу өчен авыл территорияләрендә урнашкан мәйданчыкларны инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм төзекләндерү проектларын тормышка ашыру, авыл территорияләрен һәм авыл агломерацияләрен комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыру буенча – «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү буенча – «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен.

8. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен;

Торак урынны наемга бирү шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен;

Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен;

2020 елда авыл территорияләрендә компактлы торак йортлар салу өчен мәйданчыкларны комплекслы тәртипкә китерү проектларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен.

9. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру турында» 2018 ел, 29 май, 407 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру турында» 2018 ел, 29 май, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 8 май, 387 нче.

11. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин